# Сенсор тәрбия нәрсә ул һәм аның үсеше ни өчен шулай әһәмиятле?

**Педагог-психолог МБДОУ №122 «АБВГДейка»**
**Ванюшина Л.Н.**

0-3 яшьлек балаларда сизү органнарының үсеше бик интенсив рәвештә бара. Кечкенә яшьтәге баланың барлык яклап камил үсешен сенсор үсеш тәшкил итә.

Әйләнә-тирәдәге чынбарлыкны тулы кабул итүгә юнәлдерелгән сенсорика буенча дәресләр дөньяны танып белүнең нигезе булып торалар.

Балада акыл, физик, эстетик тәрбиянең алга китеше иң беренче чиратта сенсорик тәрбиянең үсешенә бәйле: ул ни дәрәҗәдә күрә, ишетә һәм сизә.

Сенсорик тәрбиянең әһәмияте шунда:

- интелектуаль үсешнең нигезе булып тора;
- тышкы дөнья нәтиҗәсендә алган хаотик күзаллавын җиңеләйтә;
- күзәтү сәләтен арттыра;
- чын тормышка әзерли;
- эстетик сиземләвенә позитив тәэсир итә;
- күзаллау үсешенең нигезе булып тора;
- игътибарлылыкны арттыра;
- өйрәнү эшчәнлегенең яңа алымнарыннан кулланырга мөмкинлек бирә;
- сенсор эталоннарны үзләштерүгә ярдәм итә;
- укыту эшчәнлеге алымнарын үзләштерүне тәэмин итә;
- баланың сүзлек байлыгын арттыра
- күреп, ишетеп, образлы истә калдыру үсешенә йогынты ясый.

Дидактик уеннар үз эченә баланың сенсор кабул итүен ала, беренчедән яшь, әхлак үзенчәлекләрен исәпкә ала, икенчедән ireклек принцибы, ягъни мөстәкыйль сайлау хокукы.

Көндәлек тормышта бала төрле төсләр белән очраша. Бу аның яраткан уенчыклары һәм әйләндереп алган предметлар. Шул ук вакытта бала сәнгать әсәрләрен: картина, сыннарны күрә, музыка ишетә, ләкин бу белемнәрне кабул итү, үзләштерү олылар ярдәменнән башка гына булса, аның тәэсире аз була.

Менә шушы вакытта сенсор тәрбия ярдәмгә килә. Кечкенә яшьтә балаларда төс, форма, зурлык буенча күзаллау булдырыла. Бу күзаллауларның төрле булуы әһәмиятле. Баланың барлык төр үзенчәлек белән таныштырырга кирәк: барлык төсләр , геометрик фигуралар (түгәрәк, овал, квадрат, турыпочмак, өчпочмак, шар, куб, кирпеч).

Сөйләм һәм танып белү сәләтен үстерү – күрү, сизү, тотып карау, чагыштыру юлы белән җисемнәрнең төсен, зурлыгын формасын аерырга өйрәтү.Сөйләмдә сүзләр куллану һәм аңлау – зурлыкны һәм форманы әйтү.

Урта яшьтәге балаларда сенсор этап формалаша – төс, геометрик фигуралар, берничә предметның зурлыгы, формалар буенча төркемнәргә аерырга һәм башка катлаулы эшләргә өйрәтү мөхим.